ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
**РУССКО-ОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422642, Рус Әшнәге,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт,

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail:Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Рус Әшнәге авылы №1 31.01.2020 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә, 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы 06.05.2019 елның №4 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл(шәһәр) җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Рус Әшнәге авылы,Мәктәп урамы 9а йорт, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы — В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге
авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2020 елның 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыРус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлегендә җирләү буенча 2020 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча**
**хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк- яракларны бирү һәм китерү | 2230 |
| 3. Мәетне (гәүдә калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 1020 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү), кремацияләнгән мәет калдыклары | 2874,86 |
| Барлыгы: | 6124,86 |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 31.01.2020 1 карары буенча 2 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирләү буенчаРус Әшнәге авыл (шәһәр) җирлегендә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә үлгән затның законлы вәкиле булмаганда яисә җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә алган бүтән зат булмаганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 485 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 1745 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәд калдыкларын) зиратка илтү | 1020 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2874,86 |
| Барлыгы | 6124,86 |